ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЕЛМАННАРЫНЫҢ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ – ҮЗӘКЛӘШКӘН ДИНИ ОЕШМА

# 2017 елда алып барылган дини эшчәнлеккә хисап

Казан, 2018 ел

Ислам татар халкының формалашуы һәм үсешендә төп роль уйнаган, аның холкын, гореф-гадәтләрен һәм рухи-әхлакый кыйммәтләрен билгеләгән. Бабаларыбыз күз карасыдай саклаганга күрә, иман бүгенгә көнгә кадәр татар күңелендә яши бирә. Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте үзенең максатларын шушы бәһасез олы мирасны җуймыйча халыкка җиткерүдә, мөселманнарның дин тотуга булган ихтыяҗларын, хокукларын, мәнфәгатьләрен канәгатьләндерүдә күрә. 2017 елда да башкарылган эшчәнлек шуңа юнәлдерелгән иде.

Узган хисап чоры каршылык һәм киеренкелекләргә бай булса да, шактый уңай үзгәрешләр белән хәтергә кереп калыр. Татарстан өммәте өчен ул Болгар ислам академиясе ачылуы, Нәзарәт оешуының юбилее белән, бөтен татар-мөселман Корылтае һәм… исламның җәмгыятьтәге яңа мөһим роле барлыкка килүе белән бәйле. Билгеле, сүз татар халкының милли үзенчәлеген саклап калу турында бара.

Әлеге әһәмиятле темалар турында сез ТР мөселманнары Диния Нәзарәтенең 2017 елда алып барылган дини эшчәнлегенә шушы хисаптан тулырак таныша аласыз.



بسم الله الرحمن الرحيم

# Әссәламү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкатүһ! Мөхтәрәм дин кардәшләрем!

Безнең мөфтият өчен тарихта 25-еллык юбилее белән истә калган 2017 ел үтеп китте. Чирек гасыр эчендә Татарстан өммәтендә күзгә күренерлек сыйфат һәм сан ягыннан күпләгән үзгәрешләр булды. Әмма, элеккечә үк, төп бурычларыбыз булып, Татарстан мөселман дини оешмаларын берләштерү һәм аларның эшчәнлекләрен Кәлам шәриф һәм Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Сөннәте нигезендә имам Әбү Хәнифә һәм имам Әбу Мансур әл-Матуриди гакыйдәсе юнәлешләрендә кануни яктан тәэмин итү тора.

Шуның белән бергә, 25 ел элек көн кадагында булган мәсьәләләр бүген яңача яңгыраш һәм төсмер алды. Иң беренче чиратта, сүз татар телен саклап калу һәм аны Татарстанда дәүләт теле буларак үстерү, үзебезнең рухи мирасыбызны торгызу, милли зыялылар катламын тәрбияләү өчен күп баскычлы дини һәм милли белем бирүне булдыру, мәчет һәм мәдрәсә биналарын яңарту турында бара. Милләтебезнең йөзен һәм холкын, гореф-гадәтләрен һәм рухи-әхлакый юнәлешләрен билгели торган әлеге уникаль мирасны торгызу һәм киләчәк буыннарга җиткерү — Та-

тарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең төп максаты әнә шуннан гыйбарәт.

Узган ел барыбызның исендә дә Үзәкләшкән дини оешма — Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең VII чираттагы Корылтае белән истә калыр. Аның барышында мөфтиятнең җитәкчелеге үз нәтиҗәләре турында бөтен өммәт каршысында ахыргы дүрт елга хисап тотты һәм алдагы максатчан эшләргә өстенлекле юнәлешләрне билгеләде. Корылтайда катнашучылар тарафыннан мөфтияттә эшләнә торган чараларга бердәм рәвештә хуплау белдерелде һәм киләсе чорга гамәлдәге җитәкчелеккә югары ышаныч белдерелде.

Мөфтиятнең яхшы көйләнгән эшләве, хәзрәтләрнең иңгә-иң, кулга-кул тотынып, бердәмләшеп хезмәт итүе нәтиҗәсендә Нәзарәт үз алдында торган өстенлекле бурычларны һәм гамәлләрне эзлекле, даими һәм максатчан рәвештә башкарды. Кулыгызда тотып торган әлеге хисапта без өммәтебез тормышында узган барлык мөһим вакыйгалар турында мәгълүмат китерәбез: яңа ачылган мәчетләр, теркәлгән мәхәлләләрдән башлап, Голәмәләр шурасы, Казыйлар шурасы, Аксакаллар шурасы һәм башка бик күпләрнең эшчәнлеге монда урын алган. Сез күререрсез ки: шактый кыен һәм каршылыклы булуына карамастан, 2017 елда мөфтият байтак казанышларга иреште. Әмма менәсе үрләр алда әле. Киләсе елга безнең алда түбәндәге төп максатлар тора:

- Хәнәфи мәзһәбен саклау
- Татар дини мирасны торгызу һәм үстерү
- Дин әһелләренең җәмгыятьтәге абруен күтәрү
- Традицион Исламның асыл кыйммәтләрен пропагандалау.

Шушы бурычларны башкарып чыгару өчен бездән иң әүвәл үзара килешеп һәм киңәшләшеп эшләү таләп ителә. Тугрылык белән янәшәдә барганда гына профессионализм үзенең иң югары дәрәҗәсенә җитә ала. Дингә, өммәткә, милләткә, ватанга карата тугры булып, чиста вөҗдан белән, бергә эшләргә язсын иде!

Адәм баласына аның иң шатлыклы һәм иң авыр минутларында терәк булып һәрвакыт хәзрәт тора. Бу безнең олы миссиябез — шатлыкларны һәм кайгыларны уртаклашу. Шуңа Аллаһы Тәгалә Сезне һәм Сезнең якыннарыгызны хәерле гамәлләр һәм ниятләр өчен үзенең рәхмәте белән бүләкләсә иде.

كَامِـلُ سَمِيعُ اللهِ بِـنُ إِسْـكَنْدَرَ

**Олы ихтирам һәм изге догалар белән,**
**ТР мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин**



6

# ҮДО –
# ТР МДН
# турында
# белешмә
# мәгълүматы

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте 1992 нче елда республикабыз мөселманнары корылтае карары белән оеша. Оешманың рәисе итеп мөфти Габдулла Галиуллин сайлана. 1992 нче елның 15 нче сентябрендә Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте юридик теркәлү уза.

Татарстан өммәте тарихында мөһим вакыйга булып 1998 нче елның 14 нче февралендә Казанда узган Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең III Корылтае тора. Берләштерү корылтае дип аталган әлеге съезд ТР МДН белән төбәк Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтен берләштерергә ярдәм итә (әлеге ике оешма үз эшчәнлеген Татарстанда 1994 нче елдан алып барган була). Берләштерелгән мөфтиятнең рәисе итеп мөфти Госман Исхаков сайлана.

Корылтайда кабул ителгән карарлар нәтиҗәсендә, 1998 нче елда Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте Татарстан Республикасы юстиция министрлыгы органнарында теркәлү уза.

Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте (ТР МДН) — Татарстан Республикасы мөселманнарының иң югары Үзәкләшкән дини оешмасы.

## ТР МДН дини эшчәнлеге:

- Аллаһы Тәгалә иңдергән изге Коръән;
- Мөхәммәд пәйгамбәр ﷺ сөннәте;
- Әбү Хәнифәнең дини юнәлеше белән туры килгән Коръән һәм Пәйгамбәребез сөннәтенә ияргән факиһ һәм голәмәләрнең иҗтиһатында чагылган шәригать кануннары;
- Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Конституцияләре, 1997 елның 26 нчы сентябреннән 125-ФЗ номерлы «Вөҗдан иреге һәм дини берләшмәләр» Федераль законы, башка норматив-хокукый актлар һәм ТҖ МДН Уставы нигезендә тормышка ашырыла.



## ТР МДНның төп вазифалары:

- Ислам динен үстерү һәм тарату максатыннан, Татарстан Республикасының мөселман дини оешмаларын берләштерү;
- мөселман дини оешмаларының кануни бердәмлеген Коръән һәм Сөннәт нигезендә, Әбү Хәнифә традицион хокук мәктәбенә яраклаштырып тәэмин итү;
- республиканың мөселман берләшмәләренең рухи потенциалын көчәйтү һәм әхлакый нигезләрне ныгыту;
- тәрбия һәм белем дәрәҗәсен күтәрү, югары әхлаклы һәм гыйлемле шәхесләр әзерләү максатыннан җәмгыятьтә рухи-әхлакый нигез булдыру;
- җәмгыятьтә конфессия-, халыкара татулыкка һәм килешүгә ирешү;
- Татарстан Республикасы мөселманнары һәм мөселман дини оешмаларына республикада законлы хокукларын, аларның мәнфәгатьләрен кайгыртуда һәм Ислам динен таратуны тормышка ашыруда булышлык күрсәтү.

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте бүгенге көндә үз эченә түбәндәге административ-территориаль бүлекчәләрне ала:

- 9 казыят;
- 48 район мөхтәсибәте;
- 1415 теркәлү узган мәхәллә;
- 9 мәдрәсә, Россия ислам институты;
- Казан ислам институты;
- Болгар ислам академиясе.

Бүгенге көндә Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте составына 1430 мәчет керә. 2017 елда 20-дән артык яңа мәчет ачыла.

Татарстан территориясендә 700дән артык мәктәб бар, аларда 30000 шәкерт гыйлем ала һәм 1500 кеше остазлык итә.

10

# Татарстанның бердәм һәм бердән-бер мөфтиятенә – 25 ел

2017 елның 15 сентябрендә ТР Мөселманнарының Диния Нәзарәте барлыкка килүгә 25 ел тулды. Нәзарәт бүген Хәнәфи мәзһәбе һәм Матуриди гакыйдәсе кысаларында, бай татар дини мирасына таянып, традицион Ислам базасында Татарстанның барлык мөселман җәмгыятен берләштерү һәм үстерүдә зур эш башкара. Әмма хәзерге олы абруйны казану өчен, мөфтияткә озын һәм сикәлтәле юл узарга туры килә.








VII
ТАТАРСТАН
МӨСЕЛМАННАРЫНЫҢ
КОРЫЛТАЕ



1990нчы елларда башланып киткән үзгәртеп кору процессының беренче еллары республика мөселманнарының дини ихтыяҗларын канагатьләндерү өчен зур мөмкинлекләр ача. Татарстанда ачылган мәчетләрнең һәм мәдрәсәләрнең, теркәлгән мәхәлләләрнең саны моңарчы күз алдына да китерә алмаслык тизлек белән арта. Ләкин дини оешмалар һәм уку йортлары күбәйгән саен, аларның мәнфәгатьләрен кайгыртучы оешманың кирәк булуы ачыклана. 1992 елның 22 августында Яр Чаллыда Россия Үзәк Диния нәзарәтеннән мөстәкыйль булган Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең гамәлгә кую корылтае була. Аның рәисе итеп Казанның «Печән базары» мәчете имам-хатыйбы, Татарстандагы ислам үзәге лидеры Габдулла хәзрәт Галиуллин сайлана. Яңа мөселман оешмасы хакимият тарафыннан танылa һәм 1992 елның 15 сентябрендә рәсми рәвештә теркәлә. Әмма алга таба Татарстан өммәтен тагын бер хәлиткеч вакыйга көтә: 1998 нче елның 14 нче февралендә Казанда Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең III Корылтае уза. Соңыннан ул күпләрнең хәтерендә берләштерү корылтае дип истә калачак. Әлеге съезд 1994 нче елдан алып Татарстанда эшчәнлекләрен берьюлы алып барган ике мөфтиятне — ТР МДН һәм мөселманнарның төбәк Диния нәзарәтен берләштерә. Берләштерелгән мөфтиятнең рәисе итеп мөфти Госман Исхаков сайлана.

Гомумән, Татарстан тарихында бүгенге көнгә кадәр дүрт мөфти эшләгән. Аларның һәркайсысы татарлар арасында ислам үсеше елъязмасында тирән эз калдыра һәм үз вакыты өчен бәяләп бетергесез роль уйный. Габдулла хәзрәт Галиуллин Нәзарәтне оештыруга зур өлеш кертсә, Госман хәзрәт Исхаков күпсанлы мәчетләрнең һәм дини оешмаларның ачылуын тәэмин итә. 2011 елда мөфти итеп сайланган Илдус хәзрәт Фәез исә үз эшчәнлеген дини экстремизм һәм терроризм белән каты көрәшкә багышлый. Моннан 5 ел элек Диния Нәзарәтен җитәкләгән Камил хәзрәт Сәмигуллин дини мәгарифне үстерүгә һәм татар дини мирасны саклап калуга күп тырышлык куя һәм әлеге җитди эш башкаруны дәвам итә.

Оешкан вакытта Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте каршына төп бурыч итеп дини оешмаларны берләштерү, аларның эшчәнлеген Коръән һәм Пәйгамбәребез Мөхәммәднең ﷺ сөннәтенә, имам Әбү Хәнифә юнәлешенә нигезләп, бердәй кануни үрнәккә китерү игълан ителә. Хәзер республикада бердәм һәм бердән-бер булуы мөфтиятне Россиянең башка төбәкләреннән уңай яктан аерып тора.

Чирек гасыр эчендә, нәзарәт 1500гә якын мәчетне һәм аларда хезмәт итүче шуның кадәрле үк имамнарны үзенең канаты астына туплый. Соңгы 4 ел эчендә генә дә республикада 50дән артык яңа мәчет ачылды. Бүгенге көндә Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте Россиядә мәхәлләләр саны буенча икенче урынны били.

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең 25 еллык эшчәнлеге нәтиҗәсендә республикабызда ислам үсеше яңа баскычка күтәрелде, динебез яңадан җәмгыятебезгә әйләнеп кайтты. Бүген Нәзарәт иң нәтиҗәле төбәк мөфтияте позициясендә нык тора һәм җәмгыятьтә конфессияара һәм милләтара тынычлык һәм бердәмлеккә ирешү, Татарстан Республикасы мөселманнарына законлы хокукларын һәм ирекләрен тормышка ашыру юнәлешендә уңышлы эшләвен дәвам итә.

14

# Казыйлар шурасы эшчәнлеге

Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте казыяте 9 зонага бүленгән, аларның һәрберсе үз чиратында 5–6 муниципаль районнан тора. Казыйларга уртача 40 яшь. Алар барысы да дини һәм югары дөньяви белемгә ия. Казыйлар үз эшчәнлекләрен Шура турындагы Нигезләмә һәм Диния Нәзарәте Уставына нигезләнеп алып баралар. Казыйлар шурасының эчтәлекле эшчәнлеге шуны әйтергә мөмкинлек бирә: Татарстанның казыят системасы Үзәк Россиядә үрнәк булып тора.

Имамнар арасында бәхәсле мәсьәләләрне чишү өчен оештырылган әлеге структура 2017 елда даими рәвештә, айның һәр икенче дүшәмбесендә үткәрелеп торучы Казыйлар утырышларында гади мәхәллә кешесенең икътисади, эшлекле, милек һәм гаилә конфликт ситуацияләрен һәм ислам йолаларын башкару тәртибе буенча мәсьәләләрне карады. Шунысы әһәмиятле: җыелышлар Казанда гына түгел, Казыйлар Шурасының Төньяк, Көнчыгыш һәм Төньяк-көнчыгыш төбәкләрендә дә күчмә утырыш буларак үткәрелде. Мондый рәвештә очрашулар казыйларга урындагы проблемаларны үз күзләре белән күреп танышырга һәм халык белән очрашып сөйләшергә мөмкинлек бирә. 2018 елда шундый күчмә утырышлар Кама буе, Төньяк-көнбатыш Төньяк төбәкләрендә узачак. Моннан тыш, һәр казыяттә ачык ишекләр көне игълан ителәчәк.



Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев үзе дә районнарда дини вәзгыятьне контрольдә тоту максаты белән Татарстан мөхтәсибәтләрендә имамнарны борчыган мәсьәләләр буенча инспекция белән сәфәр кылуны хуп күрә. Хәзрәт узган елда республиканың 23 районына эшлекле сәфәр кыла, халык белән 33 турыдан-туры очрашуда катнаша, төрле социаль төркемнәр — укучылар һәм шәкертләр, ата-аналар, укытучылар, тәрбиячеләр, хатын-кызларга, яшь гаиләләргә 60-лап вәгазь сөйли, милли зыялылар, галимнәр, җитәкчеләр алдында теге яки бу мәсьәлә буенча үз фикерен белдереп чыгыш ясый. Баш казыйның күпьеллык тәҗрибәсе һәм белемнәре Татарстаннан читтәге төбәкләрдә дә зур ихтыяҗга ия. Ульян, Самара, Мари иле, Киров өлкәләре өммәте белән ул шулай ук даими очрашып тора.

Моннан тыш, казыйлар халыкка аңлату эшләре алып бару максатыннан массакүләм мәгълүмат чаралары белән тыгыз элемтәдә тора. Һәр татар йортында яңгыраган Болгар радиосы дулкыннары аша Татарстанның баш казые дин кардәшләргә вәгазьләр сөйли, газета-журналларның битләрендә укучыларны кызыксындырган сорауларга аңлаешлы итеп җаваплар бирә.

Әмма, билгеле, казыйлар үзләре өчен иң мөһим эш юнәлешен гаилә кыйммәтләрен саклауда күрәләр. Үткән елның казанышлары арасында «Имамнар тарафыннан никахлар укылганда ислам хокукы кагыйдәләрен куллану турында» Нигезләмәне эшләү аерылып тора. Голәмәләр шурасы белән әзерләнгән әлеге документ хатын-кызларның хокукларын яклау һәм гаилә институтын ныгыту максатларыннан чыгып эшләнде. ТР МДН Казыйлар шурасы һәм һәр казыят каршында Гаилә мөнәсәбәтләрен саклау Комиссиясен һәм аның хакимнәре өчен хәтта махсус инструкцияне булдырды.


ЧЫГУ



18

# Аксакаллар шурасы эшчәнлеге

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Аксакаллар шурасы эшчәнлеген иң тәҗрибәле һәм зирәк, мөселманнар арасында олы абруй казанган һәм мөхтәрәм, милли һәм дини гореф-гадәтләрне төптән белүче һәм ихластан аларны сакларга омтылучы дин кардәшләребез тәэмин итә.




КАЗАН ХАННАРЫ
ТӨРБӘСЕ
МАВЗОЛЕЙ
КАЗАНСКИХ ХАНОВ



Үткән елның мөһим бер вакыйгасы Аксакаллар шурасы әгъзалары ярдәме белән мәңгелеккә тарихта калачак. Ул да булса, Казан Кремле биләмәсендә археологик казынулар алып барылган чакта табылган һәм 20 елдан артык Тарих институты киштәләрендә яткан Олугъ Мөхәммәднең улы Мәхмүт хан һәм Ибраһим ханның улы Мөхмәт Әмирхан ханның һәм аларның якыннарының җәсәдләрен җир куенына иңдерү. Җирләү аксакаллар тырышлыгы белән мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендә Шаригать кануннары нигезендә Сөембикә манарасы каршында оештырылды.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов карары буенча республиканың мөселман зиратларын реставрацияләү һәм төзекләндерү буенча масштаблы программа да үткән елда үз эшен уңышлы дәвам итте. Программа кысаларында Кукмара районы зиратлары һәм Казанның Иске таш мәчете янындагы зират тәртипкә китерелде, Архиерей дачасы тирәсендә Болгар һәм Казан ханнары һәм шул чорның билгеле шәхесләре җирләнгән зиратны өйрәнү эше дә алып барыла. Гомумән, 2017 ел эчендә уннан артык зират тәртипкә салынды.

Аксакалларның тагын башка эш юнәлешләре булып Татарстанның сәламәтлек саклау министрлыгы белән бергәлектә сырхауханәләрдә намаз бүлмәләрен, хәләл туклану мөмкинлеген оештыру дә тора.

22

# Голәмәләр шурасы

Голәмәләр шурасы — Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең киңәшмә органы, махсус рәвештә фәнни-дини өйрәтмә мәсьәләләрен өйрәнү һәм чишү максатыннан булдырылган. Голәмәләр шурасы бүгенге көндә Татарстан һәм Россия өммәте социаль-икътисади үсешенең өстенлекле юнәлешләрен тормышка ашыруда актив катнаша.



2017 елда Голәмәләр шурасы эшчәнлеге банк, инвестиция һәм социаль өлкәләрне күздә тотып, аларга Ислам канунnарыннан чыгып бәя бирде, шулай ук дини йолалар һәм тәҗрибәләр буенча мәсьәләрне карады. Голәмәләр тарафыннан төрле эзләнүләр алып бару һәм рәсми карарлар чыгару нәтиҗәсендә Татарстан һәм Россия күләмендә зур әһәмияткә ия берничә проект тормышка ашырыла. Алар арасында — «АК БАРС» БАНК ААҖ белән уртак ислам кануннары буенча финанс хезмәтләр һәм хәләл продукция җитештерү өчен аерым технологияләр.

Моннан тыш, Шураның эш төркеме тарафыннан торак-төзелеш кооперативлары, иминиятләштерү компанияләре эшчәнлекләре анализланды, мөселман календаренең истәлекле бәйрәм көннәре билгеләнде, дини йолалар стандартлаштырылды, имамнар һәм казыйлар өчен никахларны теркәү һәм талак мәсьәләләре буенча кагыйдәләр җыентыгы бастыру өчен әзерләнде.

Татарстан голәмәләре эшчәнлеге чит илләрдә югары бәяләнүен шулай ук Шура әгъзасы Рөстәм хәзрәт Нургалиевның фәтвалар буенча Евразия ислам советының рәис урынбасары булып сайлануы да күрсәтә.





26

# Дини мәгариф

Диния нәзарәте тырышлыгы белән үткән гасырның 90нчы еллар башында торгызыла башлаган ислам мәгарифе бүген үзенең ренессанс чорын кичерә дисәк, һич арттыру булмас.

Бүгенге көндә ислам мәгариф системасы тулысынча формалашты дип әйтергә була. Мөселман белем бирү оешмалар, башкарылган аудит нәтиҗәләре күрсәткәнчә, җитәрлек дәрәҗәдә материаль-техник базага, мөгаллимнәр составына ия булып тора, укыту кабул ителгән мәгариф стандартлары буенча алып барыла.

Ел саен республика мәчетләре каршындагы махсус курсларда якынча 30 мең кеше гыйлем ала. Аларга 1500дән артык остаз ислам нигезләре буенча белем бирә. Татарстанда 9 мәдрәсә, Россия ислам университеты һәм Болгар ислам академиясе эшли, аларда 220 мөгалллим укыта һәм барлык бүлекләр буенча 4 мең шәкерт гыйлем ала.

Барлык дини уку йортлары да мәгариф министрлыгы биргән лицензия нигезендә үзенең эшчәнлеген алып бара.





Мөфтиятнең аерым эш юнәлеше булып югары дәрәҗәле имамнар әзерләү тора. Профессиональ тәҗрибәләрен арттыру һәм квалификацияләрен үстерү максатыннан, имамнар һәм мәчет каршында эшләп килгән курсларның мөгаллимнәре өчен Диния нәзарәте Россия ислам университеты базасында квалификацияне күтәрү курслары һәм аттестация оештырды. 2017 елда республика авылларында яшәүче һәм дини эшчәнлек алып баручы яшь дин әһелләренә матди яктан булышлык күрсәтү максатыннан Диния нәзарәте 37 грант бирде.

Мөгаллимнәр арасында ислам һәм шәригать фәннәре буенча магистр яки фән докторы дәрәҗәсендәге белгечләр тәрбияләү максатыннан ватаныбыздагы дин тәгълиматы мәктәбенең «йөзек кашы», чит илләрдәге дини белем бирү учреждениеләренә лаеклы алмаш булырлык Болгар ислам академиясе ачылды. Аның эшләп китүе — Россия дини мәгариф өчен яңа чор. Шулай итеп, бүгенге көндә Татарстан Республикасы дини белем бирү системасы дүрт баскычны тәшкил итә. Ул да булса: башлангыч дини белем бирүче мәчет каршындагы курслар, урта дини белем бирүче мәдрәсәләр, югары дини белем бирүче Россия ислам институты һәм Казан ислам институты һәм магистрларны әзерләүче Болгар ислам академиясе.

Әмма уңышлы эшләп килгән белем бирү системасы бер урында таптанып тора алмый. Бүгенге үзгәрүчән заманда эшләп килгән мәдрәсәләрнең эшчәнлеген һәрдаим камилләштереп тору зарур. Әнә шул сәбәпле, нәтиҗәле эшләтү максатыннан алдагы елларда төзелгән дини мәгарифнең үсеш юнәлешләрен билгеләгән фундаменталь программалар тулыландырылып тора. 2017 елда «Урта һөнәри дини белем стандартлары» һәм «Дини тәрбия программалары» шундыйлардан булды. Ул программалар буенча, безнең дини мирасыбызга таянып, 50дән артык китап һәм дәреслекләр әзерләнде.

Даими рәвештә урта һөнәри мәдрәсә мөгаллимнәренең гыйлем дәрәҗәсен күтәрү ниятеннән төрле фәннәр буенча курслар һәм тренинглар уздырыла. Мәдрәсәләрнең җитәкчеләрен «Менеджмент» юнәлеше буенча курсларда квалификацияләрен үстерү дә бу өлкәдә гаять мөһим булды. Халыкта зур мөселман педсоветы дигән исемне казанган Халыкара мөгаллимнәр форумын уздыру исә системаны төрле як күзлегеннән чыгып өйрәнергә һәм үстерергә мөмкинлек бирде. Шушы ук максатны үз алдында «Мөселман белем бирү йортларында инновацион технологияләр» V Халыкара фәнни-гамәли конференциясе дә тотты.


Яшьләрне тәрбияләү белем бирү учреждениеләренең тагын бер мәсьәләсе булып тора. Иң яхшы студентларга бирелә торган Мөфтинең исемле стипендиясе сәләтле мөселман яшьләрен кызыксындырырга һәм дини эшчәнлеккә профессиональ нигездә җәлеп итәргә булышса, «Бүгенге заман яшьләре һәм Россия халыкларының рухи кыйммәтләре» студентлар конференциясе, «Таян Аллага» әдәби бәйгесе, Якупов укулары, Саматов укулары, төрле түгәрәк өстәлләр һәм тематик очрашулар аларны ачык, җаваплы, иҗади шәхес итеп үстерергә ярдәм итә.

30

# Коръәнне өйрәнү

Коръән ул — Раббыбыз Аллаһы Тәгалә иңдерелгән илаһи изге Китаптыр. Коръәнне һәм аның үзенчәлеген беркем дә кабатлый, хәтта күп вакыт узганнан соң, бер генә оста шагыйрь дә Коръән кебек әсәрне иҗат итә алмады. Әмма Изге Китапны халык арасында популярлаштыру, тәфсирләр әзерләү, Коръән-хафизларның классик мәктәбен торгызу һәм иҗазалы хафизлар булдыру эшчәнлеген Диния Нәзарәте җаваплы, күпьяклы, эзлекле һәм даими рәвештә башкара.






Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин карары белән булдырылган Коръән өйрәнү бүлеге үзенә күрә бер зур казаныш булып тора. Әлеге структураның иң олы хезмәте — 2016 елда Коръәннең «Каләм Шәриф» яңа басмасын бастырып чыгару. 2017 елда исә әлеге басма Россиядә ислам үсеше тарихына кереп калды — ул рәсми рәвештә дөньякүләм стандартларга тәңгәл килә дип танылды. Коръән Сүриянең вакфлар министрлыгы каршындагы Коръән эшләре буенча Югары комиссиясе тикшерүен уңышлы үтеп, халыкара стандартларга яраклык турындагы Шәһадәтнамәгә ия булды. Әмма Нәзарәт шушы казанышта туктап калмыйча, Коръәннең өченче, яңартылган һәм камилләштерелгән басмасын әзерләүне дәвам итә. Шуның белән беррәттән ел буе Нәзарәт белгечләре тарафыннан Коръәнне рус һәм татар телләренә тәрҗемә итү эшләре алып барылды.Республикада Коръән уку бәйгеләре дә әйтеп бетергесез әһәмияткә ия. Конкурс Диния Нәзарәтенә талантлы Коръән-хафизларны барларга һәм Изге Коръәнне уку традициясен үстерергә ярдәм итә.


КАМИЛЬ ХАЗРАТ
САМИГУЛЛИН



34

# Татар рухи мирасны торгызу

Бөек татар мәгърифәтчесе Шиһабетдин Мәрҗани әйткән:


«Өч төрле әйбер диндә булмаса да, динне саклый. Алар: милли тел, милли кием һәм милли гореф».


Олугъ галимнең шушы сүзләре белән 2017 елда Диния Нәзарәтендә күп кенә эшләр башланды һәм башкарылды.




Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин татар телен саклау, өйрәнү һәм үстерү мәсьәләләрен күтәреп, татар халкына һәм мөселманнарга, яшьләр һәм ата-аналарга туган телне өйрәнергә өндәп мөрәҗәгатьләр белән чыга. Алай гына да түгел, Татарстан Республикасы мөселманнары Дини нәзарәтендә татар телле мохит булдырып, мөфтиятнең эчке һәм тышкы бәйләнешләрен, шул исәптән аралашуны һәм эш кәгазьләрен алып баруны Татарстан Республикасы эчендә ике дәүләт телендә башкаруны оештыра.

Нәзарәтнең тагын бер мөһим башлангычы булып Республика мәчетләрендә татар телен өйрәнү буенча «Без — татарлар» укыту программасын, смартфоннар өчен Telegram хәбәрләшү системасында махсус «Татарский для начинающих» дип исемләнгән һәм иске татар телендә каналларын булдыру, иҗтимагый урыннарында файдалану өчен дини терминология кертелгән рус-татар һәм татар-рус сөйләүлеген әзерләү, татар телен интернет челтәрендә, аерым алганда социаль челтәрләрдә, пропагандалау һәм мәгълүмати кампания алып бару өстендә эшләде. Шулай ук Татарстан Республикасының барлык мәчетләрендә дә туган телне өйрәнүнең һәм саклауның әһәмияте турында җомга вәгазьләре уку киң җәмәгатьчелек, татар зыялылары, укытучылар һәм республика җитәкчелеге тарафыннан олы мактауга лаек булды.


Channel Info
Татарский для начинающих
1949 members
t.me/tatyaz
Link
"Татарский для начинающих" - это обучающий телеграмм-канал в помощь в изучении татарского языка. Ресурс для начинающих.
About
Показывать уведомления
ПРОСМОТРЕТЬ КАНАЛ
31 photos
4 videos
6 shared links
28 voice messages
Покинуть канал
Пожаловаться


Channel Info
315 members
t.me/kadimca
Link
About
Показывать уведомления
ПРОСМОТРЕТЬ КАНАЛ
24 photos
21 files
Покинуть канал
Пожаловаться


38

# Дини дәгъват һәм экстремизмга каршы көрәш

Ислам — камил дин, пакь, намуслы һәм күркәм гамәлләр дине. Диния Нәзарәте дә Татарстанда гына түгел, Россия күләмендә дә исламның «визит карточкасы» булып тора, аның буенча динебез турында фикер йөртәләр, нәтиҗәләр чыгаралар. Шуңа күрә аның эшчәнлеге — үзе бер дәгъват дисәк тә була.

Нәзарәтнең дәгъват юнәлеше ни рәвешле тормышка ашырыла соң? Ул үз алдына әхлакый кыйммәтләр һәм исламның матурлыгын тарату, яшьләрдә белемгә омтылу, якыннарыңа игътибарлы булу, күрше халыкларга хөрмәт белән карау, милли гореф-гадәтләргә һәм мәдәнияткә, туган телгә мәхәббәт тәрбияләү кебек максатлар куя. Мөфтиятнең нигезен, үзәген, төп морадын тәшкил иткән әлеге мөһим эшчәнлек мөселманнар арасында, башка диндә торган халыклар һәм дәһриләр арасында алып барыла.


«II Чтения имени Ахмадзаки хазрата Сафиуллина»
«Традиции тасаввуфа в Волго-Уральском регионе».


ИСЛАМ ПРОТИВ
ТЕРРОРИЗМА
Экстремизм
ВИДЕО
ГЛОССАРИЙ
Что стало причиной внутреннего раскола в Исламе?
КАК ВЕСТИ СЕБЯ ПРИ ТЕРАКТЕ?
Неисламская идеология «Исламского государства»


Шиһабетдин Мәрҗани
тууына
200
ел
1818-2018
«АЗАН» ТАРИФЫ
8
СУМ/КӨНЕНӘ
SMS
4G
ЛИМИТСЫЗ 4G ИНТЕРНЕТ
ТАТАРСТАН ОПЕРАТОРЛАРЫНА ТҮЛӘҮСЕЗ SMS
Иртәнге намазга уяту
Гудок урынына түләүсез нәшид-мөнәҗәтләр
Диния назаратеннан махсус SMSлар



Православ һәм яһүдиләргә без ислам белән аваздаш булган уртак гомумкешелек кыйммәтләрне, динебезнең асылын, дустанә ягын һәм күркәмлеген аерып күрсәтәбез. Мөселманнарга һәм исламга карата туган тискәре стереотипларга каршы көрәш тә олы әһәмияткә ия. Дәһриләр арасында исә иманның өстенлекләрен һәм илаһи көчнең барлыгын мантыйкка бәйләп аңлату эше алып барыла.

Әмма иң киң колач җәйгән дәгъват эше, билгеле, дин кардәшләргә юнәлдерелгән. 2017 ел Нәзарәт тарафыннан Галимҗан Баруди елы дип игълан ителде һәм бөтен эшчәнлек әлеге мәшһүр татар галименең атаклы исеме канаты астында алып барылды. Россиянең беренче сайланган мөфтие булган шушы бөек дин әһеле турында киң катлам җәмгыятьне кызыксындырырлык итеп документаль фильм төшерелде һәм төрле мәйданчыкларда, шул исәптән телевидение чараларында да, тәкъдим ителде. Яшьләргә бай рухи мирасыбызны җиткерү максаты белән Татарстан Республикасының төрле шәһәр һәм районнарында гына түгел, хәтта Мәскәүдә дә Галимҗан хәзрәткә багышланган чаралар үткәрелде. Традицион Әхмәдзәки хәзрәт Сафиуллин укулары да, ел саен уздырыла торган Остазлар көне дә татар рухи мирасны торгызу максатында оештырылдылар.

Аерым чаралар исә мөкатдәс Болгар шәһәрен бөтен дөньяга таныта, татарларның бөек тарихы һәм мәдәнияте белән таныштыра. Ислам динен рәсми кабул иткән көнгә багышланган Изге Болгар җыены, Мәүлид бәйрәмнәре генә түгел, «Рухи ефәк юл: Иҗат. Берләшү», Мөселман белем бирү оешмалары мөгаллимнәре форумы кебек фәнни-гамәли конференцияләр өчен дә мәйданчык булып



тора.

Россия күләмендә беренче һәм бик үзенчәлекле дәгъват проекты булып кәрәзле элемтә өчен махсус «Азан» тариф планы тора. «Таттелеком» ачык акционерлык җәмгыяте белән берлектә әзерләнгән бу башлангыч киң җәмәгатьчелекнең кызыксынуын уятты. Уникаль проект Шиһабетдин Мәрҗанинең 200-еллыгы уңаеннан тормышка ашырыла һәм үз эченә берничә өстенлекне сыйдыра. Тарифта абонентны иртәнге намазга уяту хезмәте, шалтырату тавышы урынына мөнәҗәт, мөселман календаренең мөһим даталары турында хәбәр итү, хәдисләр һәм төрле бәйрәмнәр уңаеннан Татарстан мөфтие исеменнән котлау белән смс-хәбәрләр җибәрү һәм хаҗилар өчен Сәгуд Гарәбстанына ташламалы шалтырату, лимитсыз интернет каралган.

«Таттелеком» белән хезмәттәшлектә 2017 елда тормышка ашырылган проектлар арасында шулай ук махсус Ышаныч телефоны да бар. «Кайнар телефон линиясе» аша борчыган дини сорауларны телефоннан шалтыратып һәркем бирә ала.

Рухи-әхлакый кыйммәтләр, динебезнең нигезләре турында һәм экстремизмга каршы дәгъват эшчәнлеге аерым чикле аудиторияләрдә (мәктәп укучылары, төзәтү колонияләрендәге тоткыннар, мигрантлар, хәрби хезмәткә чакырылучылар, ата-аналар һ. б.) ачыктан-ачык сөйләшүләр, вәгазьләр, лекцияләр, түгәрәк өстәлләр үткәреп тә, киң катлам җәмәгатьчелек арасында массакүләм мәгълүмат чараларында



телевизион викториналар уздырып, теле-радио тапшыруларда катнашып, төрле басма һәм интернет чараларына интервьюлар биреп һәм язмалар белән чыгып та башкарылды. Татарстанның һәр мөхтәсибәтендә дәгъват бүлекчәләре булдырылып, әлеге мөһим эшчәнлек тагын да көчәйтелде.

Республикада ел саен уздырыла торган «Экстремизмга — юк!» дип исемләнгән айлык кысаларында терроризмга каршы көрәш, аны булдырмау өчен профилактик гамәлләр турында фикер алышулар, түгәрәк өстәлләр, ачык дәресләр, конференцияләр, төрле спорт ярышлары аеруча күп узды. Казан метрополитенында экстремизга каршы төшерелгән «Хозур» нәшрият йортының кыска видеороликларын трансляцияләү дә башкала халкы өчен үтә дә файдалы булды.

Бу өлкәдә махсус массакүләм мәгълүмат чаралары өчен оештырылган «СМИ-онлайн: социаль челтәрләрдә экстремизны булдырмау чаралары» халыкара фәнни-гамәли конференция аеруча игътибарга лаек. Социаль челтәрләр, массакүләм мәгълүмат чаралары кебек үк әлеге мәсьәләдә олы тәэсир итү көченә ия һәм интерактив элемтәләр алып бару өчен хәйран мөмкинлекләр тудыра. Шуларны исәпкә алып, Диния Нәзарәте әлеге «бугазны» үз максатларда файдалануны көчәйтү нияте белән төрле белгечләрне фикер уртаклашу өчен җыйды һәм катнашкан блогер һәм журналистларны уйламыйча төрле милләт һәм дин вәкилләре арасындагы мөнәсәбәтләрне бозудан сак торырга чакырды.

44


# Ислам кыйммәтләрен пропагандалау

Бүгенге көн вәзгыятендә динебезне төрле хирыслы максатларда файдаланудан саклау өчен, исламның асыл гүзәл кыйммәтләрен пропагандалау юлларын эзләү зарури.

Исламның бөеклеген һәм гаделлеген, аның матурлыгын һәм күркен киң җәмәгатьчелеккә җиткерү белән Диния Нәзарәтенең «Хозур» нәшрият йорты шөгыльләнә.

Әлеге үтә дә әһәмиятле эшчәнлек берничә юнәлеш буенча гамәлгә ашырыла.


ШУРА
№16
2017
Дини альманах
ГАЛИМДЖАН БАРУДИ
АБД АР-РАХМАН АС-СА'ДИ
МЕТОД ВЫНЕСЕНИЯ ФЕТВ
АБУ ХАНИФЫ
И ЕГО УЧЕНИКОВ
АВЫР ВАКЫТТА
УКЫЛА ТОРГАН ДОГАЛАР
КОРЪӘНДӘГЕ
ДОГАЛАР
Мәңгелеккә юл
тотучының
ахирәт
ПАСПОРТЫ
Мәет озату
йолалары
Ризаэтдин Фәхретдин


ЭЛЕКТРОННАЯ БИБЛИОТЕКА
исламской литературы

## Китаплар бастыру

«Китап — бакча, андагы язулар — шул бакчаның гөлләре», дигән Каюм Насыйри. Китап, дөрестән дә, бер буынның икенче буынга рухи васыяте, гомернең соңгы чигенә җиткән аксакалның яңа гына яши башлаган кешегә киңәше ул. Әнә шундый аксакал галимнәрнең хезмәтләрен «Хозур» нәшрият йорты күпләп бастыра.

2017 елда барлыгы 76 исемдәге китапларны дөньяга чыгарды. Аларның гомуми тиражы 54 мең данәне тәшкил итә.

Шунысы игътибарга лаек: китапларның яртысыннан күбрәге укучыларның һәм мәдрәсәләрнең күп сораулары буенча кабат бастырыла.

## Darul-Kutub.com электрон китапханәсе

Нәзарәтнең **Darul-Kutub.com** дип исемләнгән электрон китапханәсе инкыйлабка кадәрге классик татар галимнәре һәм дин белгечләренең, шулай ук бүгенге көн авторларның китапларын үз эченә ала. 2017 елда «Хозур» нәшрият китапханә сайтының бизәлешен яңартты. Сайтның яңа версиясе персональ компьютерларның барлык экраннарына, смартфоннарга һәм планшетларга яраклаштырылган һәм гади бизәлеше белән аерылып тора. Китапларны автор исемнәре, атамалары һәм категорияләре буенча эзләү уңайланды. Моннан тыш, darul-kutub порталының инглиз телдәге версиясе, һәм islam-today.ru сайтында блогы, Facebook челтәрендә үз бите эшли башлады.

Билгеле, иң мөһим казаныш булып 2017 елда фондның баетылуы тора — бүгенге көндә анда инде 854 китап, шул исәптә сирәк һәм иске хезмәтләр дә, урын алган.

## Мөселман газета-журналлары

Диния Нәзарәтенең башлангычы белән йөз еллык тарихлары булган атаклы татар басма чараларына яңадан тормыш өрелде. Милләт яшәеше, дин үсеше, телебезне саклау, әдәбиятыбызны яктырту сагында торган **«Дин вә мәгыйшәт» газетасы** һәм **«Шура» журналы** 2017 елда үзләренең тугры укучыларын яңа саннары белән куандырып торды. Шунысы әһәмиятле: алар үзләренең битләрендә әдәбият, тарих, сәнгать, мәгариф, татар милләтен борчыган дини-иҗтимагый мәсьәләләр турында бай эчтәлекле мирас калдырган. Бүген исә алар республикабыз мәчетләрендә һәм чит төбәк мөфтиятләрендә иң күп укыла торган басма чаралар рәтенә керә. Вәгазьләрне, Хәнәфи мәзһәбенә, матуриди гакыйдәсенә караган авыр мәсьәләләрне җиңел һәм үтемле итеп аңлатып, «Шура» һәм «Дин вә мәгыйшәт» матбугатлары бөтен Россия татар-мөселман өммәтенә хезмәт итә дисәк, һич арттыру булмас. Шушы ук максатларны үз алдында рус телендә чыккан **«Умма» газетасы** да тота.


РАДИО
AZAN
РАДИОСЫ


Название, адрес, сайт, телефон
Большой халяль справочник России
Гыйбадәте исламия
Тәһарәт
Намаз
Ураза
Зәкят
Корбан
Хаҗ
Сәфәр
Догалар
Намаз вакытлары
Сәхәр тәмам 03:46
Мәчетләрдә укыла 04:20
Кояш чыга 05:50
Зәвал 11:32
Өйлә намазы 11:32
Икенде намазы 15:13
Ахшам намазы 17:13
Ястү намазы 18:54
Кыйбла 12:25
05:17
AZAN
ГОЛОС
ИСЛАМА

# Мөселман радиосы һәм телевидениесе

2017 елда Нәзарәт һәм «Таттелеком» ААҖ арасында төзелгән килешү нигезендә Россиядә беренче тапкыр берничә уртак проект тормышка ашырылды. Шуларның икесе — кабельле челтәрләрдә эшләп килүче мөселман радиосы һәм телевидениесе. «Летай» абонентларының кабель телевидениесендә эфирга чыккан **«Азан» радиосы** рәсми рәвештә эшли башлады. Радио рус һәм татар телләрендә тәүлек әйләнәсе эшли. Программа челтәре 2017 елда традицион ислам кыйммәтләрен пропагандалау буенча 766 тапшыруны үз эченә алды. Шунысы мөһим: өр-яңа исемдәге 13 тапшыру үз эшен башлап җибәрде.

**«Хозур ТВ» мөселман телевидениесе** исә Диния Нәзарәтенең иң көтеп алынган һәм иң күп өметләр баглаган проекты булып тора. 2017 елда ул, ниһаять, онлайнда тәүлек буе сынаулы рәвештә хәбәр итә башлады. Моннан тыш, проектны алга таба тормышка ашыру өчен «Хозур» нәшрият йорты кабельле челтәрләрдә чыгу хокукы белән лицензиягә ия булды. Эфирга чыгару өчен 150 сәгатьлек видеоконтент төшерелде.

# Интернет челтәрендә — Ислам

Интернет челтәрендә Ислам кыйммәтләрен популярлаштыру, татар рухи мирасын саклау, яшьләрне тәрбияләү, халык арасында дини грамоталылыкны үстерү һәм экстремизмга каршы тору буенча җитди бурычларны да «Хозур» нәшрият йорты үз өстенә алды.

**Islam-Today.ru порталы** бүгенге көндә Россиянең иң популяр һәм абруйлы ислам хәбәрләре сайты булып тора. Порталга керүчеләр статистикасы моны яхшы дәлилли: порталның еллык аудиториясе 23 миллион кешегә җитте. Өстәвенә, республикакүләм конкурсларда да портал әзерләгән мәкаләләр берничә мәртәбә призлы урыннарга лаек булды.

**Terrora-net.ru** дип исемләнгән сайт та үз эшен уңышлы дәвам итте. Ул дини экстремизм темасына кагылышлы сорауларны тулысынча колачлап алган Татарстандагы бердәнбер интернет-мәйданчыгы булып кала бирә.

2017 елда «Хозур» тарафыннан шулай ук кесә телефоннары өчен 4 кушымтаны да яңартты. Болар: «**Намаз вакытлары**», «**Времена намаза**», «**ХаляльГид**», «**Гыйбадат Исламия**». Нәтиҗәдә, аларны 600 000 артык кеше үз телефоннарына күчереп ала.

Социаль челтәрләрдә экстремистлыкка каршы профилактика эшен дә «Хозур» Нәшрият йорты алып бара. Бүгенге көндә Интернет челтәрендә шундый 11 төркем эшләп килә. Аларда 1000-гә якын язма дөнья күрде. Тулаем язылучыларның санын исә 1 миллион кеше тәшкил итә.

50

# Динара һәм халыкара багланышлар

Кәлам Шәрифтә түбәндәгеләр әйтелә:

«Әй, адәм балалары! Без сезне бер ир, бер хатын итеп яраттык. Бер-берегезне өйрәнсен өчен, сезне халыкларга вә кабиләләргә аердык» («Хөҗүрәт» сүрәсе, 13 нче аять).

Ягъни кешелекнең күпсанлы милләтләргә һәм халыкларга бүленүе — ул Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте.



2017 елның 17 апрелендә Казанда чираттагы Татарстан мөселманнарының VII Корылтае узды. Бөтен өммәт алдында чыгыш ясап мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин Татарстанда төрле конфессия тарафдарлары белән уңай мөнәсәбәтләр булдыру һәм хезмәттәшлек итүне Нәзарәтнең мөһим бер юнәлеше итеп билгеләде.

Илебездә яшәүче барлык халыклар да уртак ватаныбызны саклауда һәм дәүләтчелек буларак төзүдә катнаша һәм бөек Россия милләтен барлыкка китерә. Әнә шушы идея мөфтиятнең милләтара һәм динара дуслыкны ныгыту эшчәнлегендә кызыл җеп булып сузыла.

Чит конфессияләргә карата дустанә мөнәсәбәттә торган шәхесне тәрбияләү эше 2017 елда аеруча мөселман яшьләре арасында алып барылды. Төрле конфессия вәкилләре арасында спорт ярышлары һәм турнирлар «дини түземсезлек» белән көрәштә нәтиҗәле булып чыкты. Күркәм гадәткә әйләнеп киткән уртак велокросслар, футбол һәм волейбол буенча матчлар төрле диндәге яшьләрне таныштырып кына калмыйча, аларны үзара спорт мәнфәгатьләреннән чыгып дуслаштыра да. Мәчет мөнбәрләреннән Халыклар бердәмлеге көне уңаеннан толерантлык һәм күрше милләтләргә хөрмәт белән карау турында әйтелгән вәгазьләр, түгәрәк өстәлләр, бәхәс клублары һәм әңгәмәләрнең дә әһәмияте әйтеп бетергесез.

Гомумән, Диния Нәзарәтенең бу өлкәдәге тәҗрибәсе бөтен Россия күләмендә, хәтта чит илләрдә дә кызыксыну уятты. Татарстан мөфтие



Камил хәзрәт Сәмигуллин 2017 елда әлеге тема буенча эксперт буларак күп кенә форум һәм конференцияләрдә чыгыш ясады. Аурупа Советы, Берләшкән милләтләр оешмасы, «Россия — ислам дөньясы» Стратегик караш төркеме һәм башка шундый абруйлы мәйданчыкларда Нәзарәт эшчәнлеге турында сөйләнде.

Шул ук вакытта халыкара бәйләнешләр башка мәсьәләләр буенча да актив алып барылды. Тәҗрибә уртаклашу, татар рухи мирасны өйрәнү һәм кайтару, фәнни эзләнүләр алып бару, Россия ислам үсешен тәкъдим итү һ. б. — болар барысы да чит илләр белән элемтәләрнең максатлары. Шушы мәсьәләләрне күздә тотып 2017 елда мөфти хәзрәт һәм нәзарәт вәкилләре Төркия, Үзбәкстан, Әзербәйҗан, Малайзия, Иран илләренә рәсми сәфәр кылды. Шундый бер эшлекле сәфәр нәтиҗәсендә, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин Иранның Мешхед шәһәрендәге тарихи китапханәсендә Идел буе Болгар дәүләтендә яшәп иҗат иткән галим Борханетдин Болгариның Коръән тәфсире һәм мантыйк буенча кулъязмаларына юлыга. Татарстанның Архив эше буенча дәүләт комитеты тырышлыгы белән әлеге хезмәтләрнең нөсхәләре Казанга кайтарыла һәм Комитет белән Нәзарәт арасындагы хезмәттәшлек килешүе нигезендә татар дин галимнәренә өйрәнү өчен тапшырыла.

Диния Нәзарәте үз чиратында шулай ук кунаклар өчен ишекләрен ачык тота. Палестина, Бахрейн, Марокко, Иран, Казахстан кебек дәүләтләрдән делегацияләр килеп Татарстан мөфтияте эшчәнлеге белән кызыксынып танышып киттеләр.

54

# Яшьләр сәясәте

Яшьләр сәясәтен алып барганда Диния нәзарәте үз алдына мөселман яшьләрен берләштерү, аларны рухи һәм әхлакый, физик яктан камилләштерү, милләтебезнең, динебезнең рухи кыйммәтләренә ихтирам тәрбияләү, гыйлемнәрен арттыру кебек максатларны алга куя. Шуңа бәйле рәвештә 2017 елда яңа буын мөселманнарына төрле чаралар уздырылды.





2015 елдан бирле оештырылып килгән «Мөселман яшьләре форумы» узган елда да үтте. Чара ата-бабаларыбыз ислам динен рәсми кабул иткән изге Болгар җирендә үткәрелде. Делегатлар изге җирдә палаткалы лагерьдә яшәп, биредәге Ак мәчеттә гыйбадәт кылдылар. Башка еллардан аермалы буларак, бу Форумда күбрәк Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаху галәйхи вәссәламнең тормыш юлына басым ясалды.

Чатнама суыкларга да карамыйча, узган елда беренче тапкыр кыш аенда «Мөселман яшьләре форумы» кысаларында «Коръән мәктәбе» дә үткәрелде.

«Мөселман яшьләренең фикер алышу клубы» һәм «Хатын-кызлар мәктәбе» проектлары да гадәткә кереп китеп, узган елда күп актив һәм фикер йөртә белгән катнашучыларны туплады. 15–35 яшьлек егетләр һәм кызлар арасында «Яшь вәгазьче», «Көчле звено» бәйгесе шулай ук бик мөһим роль уйный. Конкурслар мөселман яшьләренә рухи-әхлакый тәрбия бирү, аларның активлыгын арттыру һәм сөйләм осталыгын үстерү максатыннан оештырылды.

Яшьләр сәясәтен спорт чараларыннан башка күз алдына китереп булмый. Мөселман яшьләре спартакиадасы, мөселман командалары арасында хоккей ярышлары, мөслимәләр волейболы, мөслимәләр өчен бассейнда махсус көннәр булдыру, табигатькә җәяүле сәяхәтләр — болар барысы да мөселман егетләрен һәм кызларын рухи, физик яктан көчле һәм сәламәт булырга



өнди торган чаралар булды. Ләкин иң зур спорт чарасы, һичшиксез, Казанның Көрәш сараендә үтте — Мәрҗани кубогына джиу-джитсу буенча турнирында катнашырга Татарстаннан гына түгел, чит төбәкләрдән дә килделәр. Турнирның Шиһабетдин Мәрҗани исеме белән аталуы бөек татар галиме һәм мәгърифәтчесенең «кара каплан» борынгы татар-төрек сугышчан сәнгатендәге уңышлары белән һәм 2018 елда аның тууына 200 ел тулуы белән бәйле булды. Мөселман яшьләренең татарча көрәш һәм кул көрәше буенча IX берләштерелгән турниры исә Яр Чаллыда үтә һәм 100 дән артык спортчыны җыя. Чараларның икесендә дә төп приз — Хаҗга юллама.

Әйтергә кирәк, яшьләр социаль эшчәнлеккә да тартылалар. «Рамазан — изге гамәлләр ае» хәйрия акциясе, «Ак кәгазьгә — яңа тормыш» дип исемләнгән экологик проект Казанда гына түгел, республика районнарында да шактый киң таралыш алды.

Шунысы да әһәмияткә ия: Диния Нәзарәтенең барлык чаралары да яшьләр сәясәтенең бер юнәлеше булган волонтерлар хәрәкәте ярдәме белән оештырылып тора.

Гомумән, мөселман яшьләре өчен ел уңышлы тәмамлана: «Мөселман яшьләре берлеге» төбәкара иҗтимагый оешмасыны яңа сулыш белән яши башлады. Аның яңа Президенты — Казан шәһәре «Ризван» мәчете имам-хатыйбы Алан хәзрәт Панарин билгеләнде.

58

# Социаль эшчәнлек

Пәйгамбәребез ﷺ «Күршесе ач булып, ә үзе тук булган кеше мөэмин түгел» дигән. Рәсүлебезнең әлеге хәдисеннән мөселманнарга Аллаһ тарафыннан мөмкинлеге булган очракта ярдәмгә мохтаҗ кешеләрне кайгырту җаваплылыгы йөкләнгән булуы күренә.

Диния Нәзарәтенең «Зәкят» Хәйрия фонды әлеге изге гамәлне 1998 нче елдан бирле башкарып килә һәм 2017 елда зур уңышларга ирешә.



Фондның күпкырлы эшчәнлеге җәмгыятьнең социаль яктан якланмаган байтак катламнарын колачлый, ләкин иң беренче чиратта, авыру балаларга ярдәм итүне күздә тота. 2016 елда Фонд хисабына дәвалану курслары 39 балага үткәрелсә, 2017 елда аларның саны 57-гә җитте. Аларның күбесе церебраль паралич белән интеккән сабыйлар, араларында беженецлар гаиләләрендә тәрбияләнгән балалар да бар. Күпбалалы һәм мохтаҗ гаиләләрдән чыккан мәктәп укучылары исә Белем көне уңаеннан мөфти кулыннан кирәк-яраклар белән тулы 81 портфель алды.

Милләт һәм дингә карамыйча, мохтаҗларны азык-төлек һәм кием-салым белән тәэмин итү ел буе берөзлексез дәвам итте, Корбан һәм Ураза гаетләрендә һәм Изге Рамазан аенда исә элеге эшчәнлек көчәйтелде. Нәтиҗәдә, меңләгән кеше, мөселман уку йортлары һәм уннарча социаль учреждениеләргә 10 000 корбан сарыклары ите таратылды, 400-н артык гаилә ашамлык пакетлары, 1300 кеше бушлай өске кием һәм аяк киеме белән тәэмин ителде, 3000-гә якын фәкыйрь ел буе махсус Фонд оештырган Хәйрия ашларында кайнар ризык белән сыйланды. Республика күләмендә гошер сәдакаларын җыеп тарату шулай ук мохтаҗларга олы ярдәм булды.

Әйтергә кирәк, «Зәкят» фонды мохтаҗларга ярдәм итү йөзеннән матди чаралар җәлеп итү буенча төрле ысуллар куллана һәм яңаларын да файдалана.2017 елда зур казаныш булып «Добро mail.ru» Россиякүләм хәйрия интернет-мәйданчыгында эшли башлавы тора. Хәйриячелекнең төрле алымнары ярдәмендә җәлеп ителгән акчаларның барысы да авыру балалар хисабына күчерелде.

2017 елның тагын бер башлангычы булып беренче инклюзив «Йөрәкле шәһәр» гаилә фестивале тора. Фестиваль кысаларында физик мөмкинлекләре чикле балалар үзләренең иҗади сәләтләрен биюдә, шигырь сөйләүдә, җырлауда һәм тетральләштерелгән тамашада күрсәтә алдылар. Чара физик мөмкинлекләре чикле кешеләрне тулы тормышка тарту, алар белән мөнәсәбәт урнаштыру максатыннан оештырылды.

«Зәкят» Хәйрия фондыннан тыш, Диния Нәзарәте үзе дә төрле социаль проектларда катнаша. Шундыйлар рәтенә атаклы татар мәгърифәтчеләре һәм дин әһелләре җирләнгән татар зиратларында ел саен уздырыла торган өмәләр оештыру һәм кан тапшыру акцияләрендә катнашу керә. Мисал өчен, Татарстанның Кан тапшыру үзәгендә нәзарәт җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре, имамнар, мөселман уку йортлары шәкертләре һәм мөгаллимнәр Санкт-Петербург метросында булган фаҗигадә зыян күрүчеләргә һәм башка мохтаҗ кешеләргә ярдәм йөзеннән «Мөселманнар кан коймый!» дигән шигарь астында кан тапшырды.

Билгеле, Нәзарәтнең иң олы социаль проекты — ул да булса Республикакүләм ифтар. 2017 елда ул бишенче тапкыр Казанның теннис академиясендә үтте һәм анда 10 меңгә якын кеше катнашты. Ифтар мәҗлесендә күпбалалы һәм аз керемле гаиләләр, физик мөмкинлекләре чикле кешеләр, ятимнәр, шулай ук җәмәгать эшлеклеләре һәм дин әһелләре, республика районнарыннан һәм башка төбәкләрдән мөселманнар катнашты.



62

# Хатын-кызлар — дөньяның бизәге

«Ир кешене Коръән укырга өйрәтсәң, белем бер кешегә бирелә. Хатын-кызга Коръән гыйлемен бирсәң, тулы бер нәселгә белем биргән буласың»,— дип әйтеп калдырган сөекле Пәйгамбәребез ﷺ.

Шуны истә тотып һәм тагын мөселман хатын-кызларын борчыган проблемаларны чишү, гаилә идеологиясен ныгыту һәм үстерү, ислам кыйммәтләре үсешенә юл ачу кебек максатларны тормышка ашыру өчен ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең методик җитәкчелегендә Татарстанның мөселман хатын-кызлары берлеге эшләп килә.



Татарстан мөслимәләренең җәмгыятьтәге роле никадәр зур булуын, аларның активлыгы һәм гыйлемлелеген дәлилләп һәм олылап, Россия тарихында тәүге тапкыр «Россия мөслимәләре берлеге» иҗтимагый оешмасы рәисе Наилә ханым Җиһаншинага Гәүһәршад патшабикә исемендәге халыкара премия бирелә. Әлеге премия ел саен Аллаһының ризалыгын алырга омтылган һәм үз гомерен халык өчен хезмәт итүгә багышлаган активистларга бирелә. Наилә ханым премиягә дәгъва итүче 20 кеше арасыннан, жюри әгъзалары тавыш биргәннән соң, иң күп балларга ия була.

Гомумән, Берлекнең чит илләр белән багъланышлары 2017 елда шактый көчәя. Франциядә һәм Иранда хатын-кыз җәмгыятьләре белән очрашу һәм Ауропа Советында Страсбургта чыгыш ясарга җәлеп ителү, Халыкара «Илчеләрнең хәләл җефетләре» клубы эшендә катнашу шуларның иң әһәмиятләре. Берлекнең Россия күләмендә дә олы абруй казанганын Федерация Советы каршындагы Хатын-кызлар Союзы белән хезмәттәшлек килешүен төзү дәлилли.

Татарстан мөслимәләренең эшчәнлеген чит илләрдә һәм төбәкләрдә тәкъдим итүдән тыш, Берлек хатын-кызларны борчыган тормышчан мәсьәләләрне хәл итү буенча да җитди хезмәт башкара. Мисал өчен, Кризис үзәге кысаларында бирелгән консультацияләргә ихтыяҗ аеруча зур. Монда мөрәҗәгать итеп, гаиләдә килеп туган төрле каршылыклар һәм аерылышуга нисбәтле сорауларда хатын-кызлар үзләренең



хокуклары һәм бурычлары турында белешеп кенә калмыйча, психологик ярдәм дә алалар. Берлек каршында эшләп килгән Мөслимәләрне эшкә урнаштыру Үзәгенең эшчәнлегенә дә гүзәл затлар бик мохтаҗ.

Гаилә кыйммәтләрен ныгытуда да Берлекнең тырышлыклары әйтеп бетергесез. «Никах ярминкәсе», Хәләл туй ярминкәсе, ялгыз ир-атларны һәм хатын-кызларны гаилә кору максатыннан таныштыру өчен даими рәвештә оештырылды.

Шулай ук түгәрәк өстәлләр, утырышлар, әңгәмәләр форматында хатын-кызлар арасында да күп булды. «Ханымнар» клубы, мөслимәләр өчен тренинглар, «Казан абыстайлары» җыены, «Рухи матурлык мәктәбе» клубы, «Мөслимәнең баш киеме. Милли төс» түгәрәк өстәле һ.б. — шундыйлардан. Тагын балалар өчен Корбан бәйрәме, хатын-кызлар өчен Мәүлид кебек күркәм чаралар да республикадагы рухи, иҗади һәм мәгариф үсешенә әйтеп бетергесез өлеш кертәләр.

66

# Вакф үсеше

«ТР Вакф» Фонды Диния нәзарәте тарафыннан Татарстанда ислам үсеше өчен материаль һәм финанс база булдыру максаты белән оештырылды.

Мөфтият исә әлеге нигезне мөселман дини оешмалары эшчәнлегенең социаль, хәйрия, мәдәни, мәгариф һәм башка иҗтимагый әһәмияткә ия булган өлкәләрендә тиешле дәрәҗәдә ирекле кертемнәр буларак куллана.

Тарихи мирас биналарын реставрацияләү һәм алга таба карап тоту, милекне яңадан рәсмиләштерү һәм гасырлар буе мөселманнарныкы саналган объектларны өммәткә кулланылышка кайтару — «Татарстан Республикасы Вакфы» фонды 2017 елда үз эшчәнлеген шушы максатлардан чыгып башкарды.














Татарстанда вакф үсешен объектив күзаллау өчен Фонд 2017 елда Диния Нәзарәтенең күчемсез милке Реестрын төзи. Әлеге документка бүгенге көндә республика өммәтенең бөтен матди базасы тупланган. Аңа нигезләнеп, күчемсез милек рәвешендәге активларның күләмен түбәндәге саннар белән күрсәтеп була: гомуми мәйданы 5796 кв.м. булган 9 бина, гомуми мәйданы 5300 кв.м. тәшкил иткән 3 җир участогы. Тулаем алганда бүгенге көндә «ТР Вакф» фонды ярдәме белән Диния Нәзарәте карамагына кергән милек 11090 кв.м. гомуми мәйданга ия. Фонд катнашлыгында һәм аның контроле астында 10 объектта төзелеш-монтаж һәм төзекләндерү эшләре башкарылган, 28 объект буенча эскиз һәм эшче проектлар әзерләнгән. Бу коры саннар артында «Мухәммәдия», «Мозаффария», «Касимия» һәм Буа мәдрәсәләре, Казанның «Бишбалта», «Ал», «Апанай», «Галиев», «Миргазиян» һ.б. мәчетләре, шулай ук Чистай, Лаеш, Зәй кебек районнарның мәчет биналары турында сүз бара.

Олы әһәмияткә Фондның галимнәр, инвесторлар, дәүләт хакимиятенең структуралары белән тыгыз элемтәләре дә ия. Татарстан Республикасының инвестиция проектларын финанслау мәсьәләләре буенча Сәгуд Гарәбстаны һәм Ислам үсеш банкы белән бәйләнешләр, дөньядагы вакф өлкәсендәге иң яхшы белгечләрне җәлеп итеп фәнни-гамәли конференция уздыру югары нәтиҗәләргә ирешергә ярдәм итте. Болар Татарстанга ислам инвестицияләрен җәлеп итүдән кала, вакфны үстерү буенча иң яхшы тәҗрибәләрне өйрәнүгә мөмкинлек бирде.

70


# Татарстанда Хаҗ миссиясе

Пәйгамбәребез Мөхәммәднең ﷺ туган җирендә һәм Ислам дине тарала башлаган урыннарда булу барлык мөселманнарның да күңелләрен нурландыра.

Анда кеше ихласлы һәм тәкъва булырга өйрәнә.

Әнә шушы тәрбияви күзлектән чыгып, татарстанлыларга хаҗ кылу мөмкинлекләрен Диния нәзарәте зур кызыксыну белән арттырып тора.

Нәзарәт оештырган республиканың «ДУМ РТ Хаҗ» рәсми операторы бу олы һәм җаваплы миссияне башкарырга ярдәм итә.




ДУМ РТ ХАДЖ




2017 елда әлеге оператор хезмәтеннән файдаланып Татарстаннан 1700 мөселман хаҗ кыла. Узган елның иң олы казанышы итеп аларга олы бурычларын үтәү өчен югары дәрәҗәдәге мөмкинлекләр тудыруны атарга мөмкин. Хаҗиларның 30% — 40 яшькә кадәр һәм шуларның 10% изге сәфәргә икенче һәм тагын да күбрәк тапкыр бара. Иң яшь хаҗига 11, ә иң өлкәненә 88 яшь булды.

Хаҗиларны төрле белгечлектәге 12 табиб озатып барды. Алар тәүлек буе безнең ватандашларыбызга медицина ярдәме күрсәтә. Минә үзәнендә «ТР МДН Хаҗ» елдагыча аерым табиблар палаткасы урнаштырылды. Ул кирәкле барлык дарулар һәм җиһазлар белән тәэмин ителде.

Хаҗиларның иң зур төркемен мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин үзе озатты һәм каршы алып кына калмыйча, хаждагы төркем җитәкчеләренә һәртөрле консультацияләр биреп тыгыз элемтәдә торды. Татарстанлыларның Хаҗ гыйбадәтен хәнәфи мәзһәбе буенча үтәүләрен ул үзе җентекле контрольдә тотты. Ә аның ерак җирләргә җибәргән видеосәламе һәр дин кардәшнең изге сәфәрен тагын да ямьләндерде.

Әмма, билгеле, хаҗга әзерләнү ел әйләнәсе бара. Хаҗиларны укыту, Ислам Ватанына туры рейслар оештыру, Татарстанда мөселманнар арасында аңлату эшләре алып бару һәм бушлай семинарлар, хаҗиларны урнаштыру мәсьәләрен чишү, аларның иминлеген, туклану һәм торак мәсьәләсен тәэмин итү — боларның барысы да Татарстандагы «ДУМ РТ Хаҗ» рәсми хаҗ-операторының игътибар үзәгендә торды.



74

# Хәләл сәнәгате

Бүген хәләл төшенчәсе ислам дөньясы чикләрен бәреп чыгып киң таралыш алды.

Сыйфат һәм куркынычсызлыкның иң югары таләпләренә җавап биргән әлеге товар һәм хезмәтләр башка дин вәкилләрен дә кызыксындыра.

Шуңа җитештерүчеләр тарафыннан да хәләл сәнәгатенә кереп китү мөмкинлекләрен эзли һәм мәнфәгатьләрен аның үсеше белән дә тәңгәлләштерә.

Россия эшмәкәрләренә үзебезнең илдә һәм чит ил хәләл базарларында актив эшчәнлек алып барсын өчен юллар салу белән Диния Нәзарәтенең «Хәләл» стандартлары комитеты шөгыльләнә.




ЦРО-ДУМ РТ




«Хәләл» комитеты 2005 елда хәләл азык-төлек җитештерү хәрәкәте көчәя башлагач, бу эшләрне контрольдә тоту һәм алга җибәрү өчен оештырыла. Бүген Комитет Россиядә беренчелекне казанган, катгый рәвештә барлык таләпләрне үтәгән оешма буларак билгеле. Аның реестрында хәләл продукция җитештерә торган 113 сертификацияләнгән предприятие бар, шуларның 66-ы Татарстаннан булса, 47-се — Россиянең башка төбәкләреннән.

2017 ел тарихка олы вакыйга белән кереп калачак. Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин башлангычы белән Россиядә хәләл продукцияне җитештерү өлкәсендә 704 номерлы техник комитет оеша. Комитет Россия ислам институты каршында барлыкка килә. Аның рәисе итеп Болгар ислам академиясе һәм Россия ислам институты ректоры Рәфыйк хәзрәт Мөхәммәтшин, урынбасары итеп Нәзарәтнең «Хәләл» Комитеты рәисе Марат Низамов, җаваплы сәркатиб итеп Казан ислам институты проректоры Рөстәм хәзрәт Нургалиев билгеләнә. Комитет составына Россия һәм Татарстанның 67 оешмасы һәм предприятисе керә. 2017–2020 елга хәләл продукциясе һәм хезмәтләренә 15 милли стандартлар эшләп чыгару планлаштырыла. Комитетның төп максаты булып продукцияне җитештерүдә һәм «Хәләл» хезмәтләр күрсәтүдә гомумфедераль стандартлаштырылган методларны эшләү һәм гамәлгә кертү тора. Шул сәбәпле Россия товар җитештерүчеләренә таләпләр тәртипкә китерелер, товарны эчке базарда куллану мөмкинлеге барлыкка килер һәм продукцияне чит илгә экспортка чыгарырга мөмкинлекләр артыр дип көтелә. 2017 елның 6 декабрендә Комитетның Казанда беренче утырышы узды.

Шулай ук тәүге тапкыр Казанда «Россия — Ислам дөньясы: KazanSummit 2017» IX Халыкара икътисадый саммит кысаларында RUSSIA HALAL EXPO дип исемләнгән Хәләл сәнәгате Халыкара күргәзмәсе үтте. Күргәзмәне 3000 артык кеше килеп күрде. Ул Россия, СНГ дәүләтләре һәм ерак чит ил җитештерүчеләренә үз продукцияләрен күрсәтергә һәм яңа сату базарларын үзләштерергә мөмкинлек бирә.

78

# Йомгак

Әнә шул рәвешле, үз кыенлыклары һәм каршылыклары белән килгән юбилейлы 2017 ел Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния Нәзарәте өчен зур казанышларга бай булды.

Өммәт тарафыннан булган теләктәшлек, терәк һәм ышаныч белдереп, Аллаһы Тәгалә биргән ярдәм һәм тырышлык белән, аның миһербан-шәфкате белән мөфтият сөекле Пәйгамбәребез ﷺ мөбарәк сөннәтеннән тайпылмыйча үз эшчәнлеген югары дәрәҗәдә башкара алды.

Татар-мөселман рухи-әхлакый кыйммәтләр һәм татар халкы күңелендә күз карасыдай сакланган иман — бәһасез олы мирас ул.

Аны җуймыйча киләчәк буынга һәм милләткә җиткерүне Нәзарәт алга таба дәвам итәчәк, ИншәАллаһ.

2017 елда алып барылган дини эшчәнлеккә хисап

Казан, 2018 ел

www.dumrt.ru